ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» гыйнвар 2022 ел № 17

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының муниципаль милкендәге җир кишәрлекләреннән һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве, пенялар, административ штрафлар буенча бурычларын түләтүгә ышанычсыз дип тану комиссиясе турындагы карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы нигезендә, шулай ук гамәлдәге законнарны хокукый анализлау һәм мониторинглау, муниципаль хокукый актларны законнарга туры килү-килмәүгә алдан юридик тикшерү нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карарының үз көчен югалтуын танырга:

«Муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве, пенялар, административ штрафлар буенча түләтүгә ышанычсыз бурычлар буенча комиссия төзү турында» 2013 елның 12 августындагы 282 номерлы;

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве, пенялар, административ штрафлар буенча түләтүгә ышанычсыз бурычлар буенча комиссия төзү турында» 2013 елның 12 августындагы 282 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 19 декабрендәге 494 номерлы карары;

«Бурычларны исәптән төшерү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 11 августындагы 250 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында: https://agryz.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**